**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Тымытык авыл җирлеге Советы**

Тымытык авылы № 86-141 «25» ноября 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Советының 24.11.2014 ел №31 «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (18.08.2015 №15, 12.10.2018 №67-101, 25.06.2019 №79-129 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Салым кодексыныц беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 29.09.2009 ел № 325-ФЗ Федераль закон, «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

Тымытык авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Советыныц 24.11.2014 ел №31 «Җир салымы турында» карарына (18.08.2015 №15, 12.10.2018 №67-101, 25.06.2019 №79-129 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Кадастр бәясенец 0,3 проценты-торак фонд һәм торак-коммуналь комплексының инженер инфраструктура объектлары урнашкан җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексыныц инженерлык инфраструктурасы объектларына туры килмәгән объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктан тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш).»

1.2. 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Җир салымын түләүдән азат ителә:

1) Советлар Союзы Геройлары, РФ Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары һәм Дан, Хезмәт Даны орденнары тулы кавалерлары;

2) Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары, сугыш хәрәкәтләре инвалидлары, шулай ук Бөек Ватан сугышында катнашучыларның социаль гарантияләре һәм ташламалары законнар белән каралган гражданнарны;

3) «Чернобыль АЭСдәге һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» 15.05.1991 ел № 1244-1 Россия Федерациясе Законы, «Маяк»җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән РФ гражданнарын

социаль яклау турында»26.12.1998 ел №175-ФЗ Федераль Закон, «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга социаль гарантияләр турында» 10.01.2002 ел № 2-ФЗ Федераль Закон нигезендә социаль ярдәм алу хокукына ия булган физик затларны;

4) 1 һәм 2 группы инвалидларны;

5) балачактан инвалидлар, инвалид балалар;

6) мәйданнар, урамнар, тыкрыклар, юл йөрү юллары, автомобиль юллары, скверлар, парклар, һәйкәлләр, су алу скважиналары, үләт базлары, каты көнкүреш калдыклары полигоннары һәм зиратлар урнашкан гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә караган муниципаль оешмаларны.

7) Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан рәсмиләштерелгән җир участоклары өлешендә:

- авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен милеккә;

- 3 һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга милеккә җир кишәрлекләре бирү өчен йорт яны җир кишәрлекләре белән индивидуаль торак йортлар өчен даими (сроксыз) файдалануга»;

2. Әлеге карарның 1.1 пункты 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми басма – «Маяк»газетасында басылып чыкканнан соң бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aznakayevo.tatar.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Э.Х.Гыйләҗева